| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЮРТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ЮРТАУ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**К А Р А Р**

№ 16 21.03.2019ел

Татарстан Республикасы
Минзәлә районының “Юртау авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү турында Нигезләмәне раслау турында

24.07.2007 елдагы “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында”гы № 209-ФЗ Федераль законы нигезендә, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү өлкәсендә программаларны һәм проектларны башкару буенча муниципаль берәмлек вәкаләтләрен тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Минзәлә районының “Юртау авыл җирлеге”

КАРАР ЧЫГАРА:

1.Кушымта №1 нигезендә Татарстан Республикасының Минзәлә районы “Юртау авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү турында Нигезләмәне расларга.

2.Гамәлдәге карарны Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге торак пунктларының махсус мәгълүмати стендларында һәм menzelinsk.tatar.ru. рәсми сайтында урнаштыру аша халыкка җиткерергә.

3. Гамәлдәге карар рәсми төстә халыкка җиткерелү белән көченә керә.

Җитәкче: И.Ю.Кадыров

Юртау авыл җирлеге
башкарма комитетының
карарына
№ 16 от 21.03.2019ел
Кушымта № 1

**Татарстан Республикасының Минзәлә районы “Юртау авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү турында**
**Нигезләмә**

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына муниципаль мөлкәти ярдәм чаралары халыкка күрсәтелә торган хезмәтләрнең күләмен арттыруга һәм сыйфатын яхшыртуга; яңа төр эшчәнлек булдыруга һәм үстерүгә, шул исәптән инновацияле: халыкка оешмалар һәм учреждениеләр күрсәтә торган хезмәтләр дефицитын тутыру, яңа эш урыннары булдыру.

**1.2. Гамәлдәге Карар җайга сала:**

- авыл җирлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына файдалануга һәм (яисә) биләүгә тапшыру максатларында файдаланыла торган муниципаль мөлкәт Исемлегенә кертелгән

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге (алга таба – авыл җирлеге) муниципаль хосусыйлыгындагы объектларны бушлай файдалануга һәм арендага бирү рәвешендә муниципаль мөлкәти ярдәм күрсәтү тәртибен;

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмалар һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен ташламалы аренда түләвен кертү һәм исәпләү тәртибен.

1.3. Юртау авыл җирлеге кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмалар һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына муниципаль мөлкәти ярдәм чараларын түбәндәгечә куллана:

1.3.1. Авыл җирлегенең урта һәм кече эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына файдалануга һәм (яисә) биләүгә бирү максатларында файдаланыла торган муниципаль мөлкәт Исемлеге (алга таба – Муниципаль мөлкәт Исемлеге) рәвешендә билгеләнгән муниципаль мөлкәтнең махсуслаштырылган фондын формалаштыру аша;

1.3.2. Авыл җирлегенең урта һәм кече эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына муниципаль мөлкәтнең махсуслаштырылган фонды объектларын ташламалы шартларда арендага билгеләнгән тәртиптә бирү аша;

1.3.3. Авыл җирлегенең урта һәм кече эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы билгеле бер коммерциягә бәйле булмаган оешмаларга муниципаль мөлкәтнең махсуслаштырылган фонды объектларын бушлай файдалануга билгеләнгән тәртиптә бирү аша;

1.3.4. Муниципаль мөлкәтнең махсуслаштырылган фонды объектларыннан файдаланган өчен аренда түләве ставкаларын җайга салуны куллану аша.

1.4. Авыл җирлегенең урта һәм кече эшмәкәрлек субъектларына (алга таба шулай ук – муниципаль мөлкәтнең махсуслаштырылган фонды) ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына файдалануга һәм (яисә) биләүгә бирү максатларында файдаланыла торган муниципаль мөлкәт Исемлеген формалаштыру һәм раслау тәртибе гамәлдәге законнар нигезендә, Юртау авыл җирлегенең норматив хокукый акты белән билгеләнә.

1.5. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы

оешмаларга һәм кече һәм урта эшмәкәрлекнең билгеле бер субъектларына муниципаль мөлкәтнең махсуслаштырылган фонды объектларын арендага бирү тәртибе гамәлдәге Нигезләмә һәм Юртау авыл җирлеге карары белән расланган авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгы объектларына караган торак булмаган биналардан файдаланган өчен аренда түләвен бюджетка күчерү һәм аренда түләве ставкаларын исәпләү тәртибе турындагы Нигезләмә белән җайга салына.

1.6. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы коммерциягә бәйле булмаган муниципаль мөлкәтнең махсуслаштырылган фонды объектларын бушлай файдалануга тапшыру тәртибе гамәлдәге законнар һәм гамәлдәге Нигезләмә белән җайга салына.

1.7. Авыл җирлеге өчен кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан аңа ярдәм күрсәтү зарур булган өстенлекле эшчәнлек төрләре Юртау авыл җирлеге депутатлары Советы карары белән расланган, авыл җирлегендә кече эшмәкәрлекне үстерү һәм ярдәм итү Программасы белән билгеләнә.

1.8. Воровский ис. авыл җирлеге территориясендә эшчәнлек алып баручы, мөлкәти ярдәм алучы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының реестрын алып бару тәртибе гамәлдәге законнар нигезендә, Юртау авыл җирлеге башлыгы – Юртау авыл җирлеге җитәкчесенең норматив хокукый акты белән билгеләнә.

1.9. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасы – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын булдыру һәм аларга ярдәм күрсәтү өчен шартларны тәэмин итүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерүнең максатчан программаларын тормышка ашырганда муниципаль ихтыяҗлар өчен хезмәтләр күрсәтү, эш башкару, товар китерүгә заказлар урнаштыру максатларында товар яки чимал белән тәэмин итеп торучы (башкаручы, подрядчы) сыйфатында җәлеп ителә яисә үз эшчәнлекләрен алып бара, булдырыла торган коммерцияле һәм коммерциягә бәйле булмаган оешмалар системасы.

1.10. Авыл җирлегенең кече эшмәкәрлегенә ярдәм итү инфраструктурасын булдыручы оешмалар исемлеге Юртау авыл җирлеге башлыгы – Юртау авыл Советы җитәкчесенең норматив хокукый акты белән билгеләнә.

1.11. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына муниципаль мөлкәтнең махсуслаштырылган фонды объектларын ташламалы шартларда арендага бирү тапшырылган мөлкәттән файдаланган өчен гомуми билгеләнгән аренда түләвен киметү мөмкинлеген күздә тота.

1.12. Муниципаль мөлкәт арендасы Арендага бирүче һәм Арендатор арасында язмача формада төзелгән аренда килешүе буенча башкарыла.

1.13. Муниципаль мөлкәтне бушлай файдалануга тапшыру Ссуда бирүче һәм Файдаланучы арасында язмача формада төзелә торган килешү буенча башкарыла.

1.14. Муниципаль мөлкәтнең махсуслаштырылган фондына, арендага һәм бушлай файдалануга кертелгән авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгы объектларын тапшырганда Арендага бирүче һәм Ссуда бирүче вәкаләтләрен Юртау авыл җирлеге җитәкчесе башкара.

**2. Мөлкәти ярдәм күрсәтү тәртибе**

2.1. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Юртау авыл җирлегендә ярдәм күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткәндә мөлкәти ярдәм күрсәтелә.

2.2. Мөлкәти ярдәм бирелә:

1) аренда хокукына аукцион нәтиҗәләре буенча;

2) аренда хокукына, бушлай файдалануга хокукка конкурс нәтиҗәләре буенча;

3) аренда килешүен, бушлай файдалану килешүен сату-сәүдә эшен уздырмыйча төзү.

2.3. Муниципаль мөлкәтнең махсуслаштырылган фондына кертелгән муниципаль хосусыйлык объектларыннан бушлай файдалану, арендага алу белән кызыксынган кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары булган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр (алга таба – гариза тапшыручылар) муниципаль мөлкәттән файдалануга тапшыру турында гариза (алга таба – Гаризалар) белән Юртау авыл җирлегенә мөрәҗәгать итәләр.

Мәҗбүри тәртиптә билгеләнгән гаризага түбәндәге документлар теркәлә:
а) үз эшчәнлекләрен юридик зат булдырмыйча алып баручы шәхси эшмәкәрләр өчен:
- дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе;
- салым органында учетка куелу турында таныклык күчермәсе;
- шәхесне раслаучы документ күчермәсе;
- төрле дәрәҗәдәге бюджетларга салымнар буенча һәм муниципаль мөлкәттән файдаланган, шул исәптән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве буенча бурычлар булмауны раслаучы документлар;
- билгеләнгән форма буенча анкета
б) юридик затлар өчен:
- учредитель документлары күчермәләре;
- юридик затның дәүләт теркәве турында таныклык күчермәсе;
- салым органында учетка куелу турында таныклык күчермәсе;
- җитәкченең яисә юридик затның вәкиле вәкаләтләрен раслаучы документлар;
- - төрле дәрәҗәдәге бюджетларга салымнар буенча һәм муниципаль мөлкәттән, шул исәптән җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве буенча бурычлар булмауны раслаучы документлар;
- билгеләнгән тәртиптә анкета.
Юртау авыл җирлеге муниципаль мөлкәтне арендага тапшыру турындагы мәсьәләне тикшерү өчен кирәкле булган башка документларны таләп итәргә хокуклы.
2.4. Юртау авыл җирлеге кергән Гаризаларны теркәүне башкара һәм Гаризалар тапшырылган көннән соң бер атна эчендә мөлкәти ярдәм күрсәтүгә кергән Гаризаларны карау буенча комиссия утырышын оештыра.
2.5. Мөлкәти ярдәм күрсәтүгә кергән Гаризаларны карау буенча даими гамәлдәге Комиссия (алга таба – Комиссия) Юртау авыл җирлеге башлыгы – Юртау авыл җирлеге җитәкчесенең норматив-хокукый акты нигезендә булдырыла һәм гамәлдә була.
2.6. Комиссия әгъзалары утырышта катнашкан күпчелек тавыш белән комиссия карар кабул итә, шул ук вакытта анда комиссия әгъзаларының кимендә 2/3 өлеше катнашкан булса, утырыш гамәлдә санала. Комиссия утырышы беркетмә белән рәсмиләштерелә.
2.7. Мөлкәти ярдәм күрсәтү турында кергән Гаризаларны тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:
1) аренда хокукына аукцион уздыру турында;
2) аренда хокукына, бушлай файдалануга хокукка конкурс уздыру турында;
3) муниципаль мөлкәтне арендага, сату-сәүдә эше уздырмыйча бушлай файдалануга тапшыру турында;
4) гамәлдәге законнарда билгеләнгән очракларда муниципаль мөлкәтне бушлай файдалануга, арендага бирүне кире кагу.
Кабул ителгән карар турында Гариза бирүче биш көн эчендә язмача хәбәр ала.
2.8. Мөлкәти ярдәм турында Комиссия кабул иткән карар нигезендә:
2.8.1. Гамәлдәге Нигезләмә белән билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, Юртау авыл җирлеге башлыгы – Юртау авыл Советы җитәкчесенең расланган карары белән, Юртау авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен арендага тапшыру тәртибе турында Нигезләмә белән, билгеләнгән гамәлдәге гражданлык законнары тәртибендә аренда хокукына, бушлай файдалану хокукына сату-сәүдә эше (аукцион, конкурс) уздырыла;
2.8.2. Юртау авыл җирлеге тарафыннан сату-сәүдә эше уздырмыйча муниципаль мөлкәти ярдәм бирүгә ризалык бирү турында үтенечнамәне монополиягә каршы органга җибәрү өчен 26.07.2006 елдагы “Конкуренциядән саклану турында”гы №135-ФЗ Федераль законның 20 маддәсе нигезендә документлар пакеты әзерләнә, һәм шундый килешү алганнан соң, аренда килешүе, Гариза бирүче белән муниципаль мөлкәттән бушлай файдалану килешүе төзелә. Муниципаль мөлкәти ярдәм күрсәтүгә ризалык бирүне монополиягә каршы орган кире каккан очракта, бут руыда Гариза бирүчегә язмача хәбәр җибәрелә.
2.9. Муниципаль мөлкәтне арендага, бушлай файдалануга алуга дәгъва итүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына таләпләр:
- Гариза бирүче билгеләнгән тәртиптә теркәлергә, гамәлдәге Нигезләмәнең 2.3 пункты

нигезендә тиешле документлар җыелмасын булдырырга тиеш;

- Гариза бирүче намуссыз арендаторлар исемлегендә булырга тиеш түгел (аренда түләүләре буенча бурычлары булырга тиеш түгел).

2.10. Юртау авыл җирлеге аукционнар, конкурслар уздыру оештыручысы булып тора.

2.11. Авыл җирлегенең муниципаль мөлкәте объектларыннан файдалану максатчан булып тора. Мөлкәтнең максатчан (функциональ) билгеләнүен аренда килешүе, бушлай файдалану килешүе билгели. Мөлкәтнең функциональ билгеләнүен Арендатор, Кулланучы тарафыннан үзгәртү Юртау авыл җирлеге ризалыгыннан башка була алмый.

2.12. Муниципаль мөлкәтне куллануга алуга дәгъва итүче кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмаларга һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына таләпләр конкурс нигезендә муниципаль мөлкәтне бушлай файдалануга, арендага биргәндә, конкурс документациясе белән билгеләнә, шул исәптән:

- законнар нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына кертү;

- авыл җирлегенең муниципаль норматив-хокукый актлары нигезендә, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасы булдыручы оешмаларга кертү;

- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының төп эшчәнлек төре буенча кимендә өч елга бизнес-планы булу;

- Юртау авыл җирлеге территориясендә өстенлек бирә торган эшчәнлек алып бару;

- авыл җирлеге территориясе өчен өстенлекле эшчәнлек төрен башкару.

Сайлау критерийлары муниципаль мөлкәт объектларының аерым төрләре өчен индивидуаль булырга мөмкин.

2.13. Муниципаль мөлкәтне арендага, бушлай файдалануга бирү шартлары конкурс документациясе, аренда килешүе, бушлай файдалану килешүе һәм гамәлдәге Нигезләмә белән билгеләнә.

**3. Муниципаль мөлкәт объектларын арендага алган өчен аренда түләве ставкаларын билгеләү ысуллары**

3.1. Махсуслаштырылган фондка кертелгән муниципаль күчемсез милек объектларыннан файдаланган өчен аренда түләве түбәндәгечә билгеләнергә мөмкин:

- Юртау авыл җирлеге башлыгы – Воровский ис. авыл Советы җитәкчесе карары белән расланган, авыл җирлекләренең муниципаль хосусыйлык объектларына караган торак булмаган биналардан файдаланган өчен аренда түләвен бюджетка күчерү һәм аренда түләве ставкаларын исәпләү тәртибе турында гамәлдәге Нигезләмә нигезендә билгеләнгән ставкалар;

- Юртау авыл җирлеге башлыгы – Юртау авыл Советы җитәкчесе карары белән расланган Юртау авыл җирлегенең муниципаль хосусыйлыгындагы объектларга караган торак булмаган биналардан файдаланган өчен аренда түләвен бюджетка күчерү һәм аренда түләве ставкаларын исәпләү тәртибе турында гамәлдәге Нигезләмә нигезендә билгеләнгән күләмдә куелган аренда түләве ставкалары;

- аукцион яисә конкурс нтиҗәләре буенча билгеләнгән аренда түләве ставкалары.

3.2. Аукционга чыгарыла торган күчемсез муниципаль мөлкәт объекты өчен аренда түләвенең старт (башлангыч) ставкасы Юртау авыл җирлеге башлыгы – Юртау авыл Советы җитәкчесе карары белән расланган, торак булмаган биналардан файдаланган өчен аренда түләвен бюджетка күчерү һәм аренда түләве ставкаларын исәпләү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә билгеләнә.

3.3. Конкурска чыгарыла торган күчемсез муниципаль мөлкәт объекты өчен аренда түләвенең старт (башлангыч) ставкасы Юртау авыл җирлеге башлыгы – Юртау авыл Советы җитәкчесе карары белән расланган, торак булмаган биналардан файдаланган өчен аренда түләвен бюджетка күчерү һәм аренда түләве ставкаларын исәпләү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә билгеләнә.

3.4. Аренда түләве күләменә түбәндәгеләр керми:

- коммуналь хезмәтләр өчен түләүләр, түләүләр әлеге хезмәтләрне күрсәтүче оешма белән Арендатор арасында төзелгән аерым килешү буенча башкарыла торган бинаны, корылмаларны техник карап тоту, яисә ул булмаганда - Баланс тотучы (Арендага бирүче) һәм Арендатор арасында хезмәтләр күрсәтүгә килешү буенча;

- исәпләү һәм күчерү гамәлдәге РФ Салым кодексы нигезендә Арендатор тарафыннан

мөстәкыйль рәвештә башкарыла торган өстәмә кыйммәткә салым;

- гамәлдәге җир законнары нигезендә Арендатор тарафыннан кертелә торган җир кишәрлеге өчен түләү.

3.5. Махсуслаштырылган фондка кертелгән күчемле милек объектларыннан файдаланган өчен аренда түләве Юртау авыл җирлеге башлыгы – Юртау авыл җирлеге җитәкчесе карары белән расланган муниципаль мөлкәтне арендага биргәндә аренда түләвен исәпләү Тәртибе нигезендә билгеләнә.

3.6. Җир кишәрлегенә аренда килешүе төзү хокукы өчен түләү Россия Федерациясе законнарында һәм авыл җирлегенең норматив хокукый актларында каралганча гомуми нигезләрдә билгеләнә.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмалар өчен авыл җирлеге Советы депутатларының норматив хокукый актлары нигезендә җир өчен аренда түләве ставкаларына киметүче коэффициентлар кабул ителергә мөмкин.

**4. Муниципаль мөлкәтне бушлай файдалануга тапшыру тәртибе һәм шартлары**

4.1. Муниципаль мөлкәтне кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын булдыручы оешмалар һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бушлай файдалануга тапшыру гамәлдәге Нигезләмәнең 2 нче бүлеге нигезендә мөлкәти ярдәм күрсәтүгә кергән Гаризаларны карау буенча Комиссия кабул иткән карар нигезендә түбәндәгечә башкарыла:

- 21.07.2005 елдагы “Концессион килешүләр турында”гы №115-ФЗ Федераль законында бирелгән тәртиптә мөлкәтне бушлай файдалануга тапшыруга конкурс уздыру;

- конкурс уздырмыйча, монополиягә каршы органның язмача формада алдан килешүе белән, муниципаль мөлкәтне бушлай файдалануга тапшыру.

4.2. Монополиягә каршы органның язмача формада алдан килешүе белән, муниципаль мөлкәтне бушлай файдалануга тапшырганда, Гариза тапшыручылар көндәшлек турында Закон нигезендә муниципаль ярдәм күрсәтү өчен кирәкле документларны Юртау авыл җирелегнә тапшыралар.

4.3. Муниципаль мөлкәтне бушлай файдалануга тапшыру турында карарлар Юртау авыл җирлеге башлыгы – Юртау авыл җирлеге җитәкчесе карарлары белән рәсмиләштерелә.

4.4. Муниципаль мөлкәтне бушлай файдалануга тапшыруны Гариза бирүчеләргә кире кагу өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

- билгеләнгән формага тәңгәл килми торган гариза тапшыру;

- гаризаларны гамәлдәге Нигезләмәнең 2.3 пунктында күрсәтелгән документлардан башка бирү;

- Россия Федерациясенең Гражданлык кодексы һәм башка федераль законнар нигезендә бушлай файдаланыла алмаган объект буларак, муниципаль мөлкәтне тапшыру мөмкин булмау;

- көндәшлек турында Закон нигезендә хуҗалык итүче субъектка муниципаль хезмәт күрсәтүгә ризалык бирү турында үтенечнамәне канәгатьләндерүне кире кагу турында монополиягә каршы органның карар кабул итүе;

- башка максатлар өчен гариза бирелгән муниципаль мөлкәттән файдалану (арендага тапшыру) турында булган карарлар.

4.5. Конкурс уздырмыйча, Гариза бирүчегә муниципаль мөлкәтне бушлай файдалануга тапшыру турында карар кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә авыл җирлеге администрациясе бушлай файдалану килешүен төзү һәм рәсмиләштерүне башкара. Муниципаль мөлкәттән файдалану шартлары һәм максатлары гамәлдәге Нигезләмә нигезендә күрсәтелгән килешү белән билгеләнә.

4.6. Кулланучы бушлай файдалану турында килешү проектын имзалаудан баш тартса, шул исәптән. язмача рәсми хәбәр алганнан соң 10 көн эчендә килмәсә, муниципаль мөлкәтне бушлай файдалануга тапшыру турындагы тиешле күрсәтмә (боерык) билгеләнгән тәртиптә көчен югалткан дип танылa.

4.7. Бушлай файдалану шартларын тикшергәндә яклар килешенә алмаган очракта, алар гамәлдәге законнар билгеләгән тәртиптә хәл ителә.

4.8. Ссуда бирүче тарафыннан муниципаль мөлкәтне тапшыру һәм аны Кулланучы тарафыннан кабул итеп алу яклар имзалаган тапшыру акты белән рәсмиләштерелә.

Кулланучының бушлай файдалану килешүендә каралган шартларда тапшыру актына кул куюдан читләшүе мондый мөлкәтне алудан баш тарту буларак карала.

4.9. Бушлай файдалану килешүе өзелгәндә Ссуда алучы закон таләпләрен, башка норматив хокукый актларны һәм төзелгән бушлай файдалану килешүе таләпләрен үтәп кулланучыга муниципаль мөлкәтне тапшыру акты буенча тапшыра.

4.10. Кулланучылар бушлай файдалануга алган муниципаль мөлкәтне төзек хәлдә тотарга (агымдагы һәм капиталь ремонтны башкаруны да кертеп), әгәр бушлай файдалану килешүендә башкача каралмаган булса, аны карап тотуга барлык чыгымнарны күтәрергә бурычлы.

Күрсәтелгән таләпләрне үтәү өчен, Кулланучылар техник хезмәт күрсәтүгә, эксплуатация чыгымнарын түләүгә килешүләр һәм башка килешүләр төзиләр.

Коммуналь хезмәтләргә түләүне Кулланучылар башкара.

4.11. Гамәлдәге Нигезләмә белән җайга салынмаган башка мәсьәләләр, казнаның муниципаль мөлкәтеннән бушлай файдалануга килешүләр төзегәндә һәм үтәгәндә килеп чыккан якларның үзара мөнәсәбәте гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә карала.

**5. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөрәҗәгатьләренә җавапларны рәсмиләштерү**

Мөрәҗәгатькә җавап тексты төгәл, эзлекле, кыска булырга, мөрәҗәгатьтә куелган барлык сорауларга җавап бирергә тиеш.

Мөрәҗәгатьтә бәян ителгән вазифаи бурычларның тиешенчә үтәлмәве турындагы факт расланган очракта, гаепле вазифаи затларга карата нинди чаралар күрелүен җавапта күрсәтергә кирәк.

**6. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөрәҗәгатьләрен карау белән бәйле рәвештә, карарларга, гамәлләргә (берни дә эшләмәүгә) шикаять бирү**

Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яисә) суд тәртибендә мөрәҗәгать каралуга бәйле рәвештә, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары мөрәҗәгать буенча кабул ителгән карарга яки гамәлгә (берни эшләмәүгә) дәгъва белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

**7. Йомгаклау нигезләмәләре**

7.1. Муниципаль мөлкәтне арендага, бушлай файдалануга бирү гамәлдәге Карарда каралганча, гамәлдәге Нигезләмә көченә кергән датадан башкарыла.

7.2. Муниципаль мөлкәтне тапшырганда якларның гамәлдәге Нигезләмәдә күздә тотылмаган барлык үзара мөнәсәбәтләрендә яклар гамәлдәге законнарның нормаларын һәм авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының хокукый актларын кулланалар.